# Нәсыйхәт

Җомга
22
февраль
2013 №21

Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән
Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы


## Яңалыклар

### ГОШЕР БӘЙГЕСЕ НӘТИҖӘЛӘРЕ

6нчы февраль көнне Гошер бәйгесенә нәтиҗәләр ясалды. Мәдрәсә җитәкчесе барлык катнашучыларга олы рәхмәтен белдерде. Җиңүчеләргә бүләкләр тапшырды. Мәҗлес чәй табыны артында дәвам итте.

### МӘДРӘСӘДӘ ТИКШЕРҮ

12нче февральдә мәдрәсәдә тикшерү булып үтте. Казан шәһәреннән килгән мөфтинең урынбасары Абдулла хәзрәт Адыгамов һәм укыту эшләре буенча җаваплы Айдар хәзрәт Карибуллин җитәкчелегендәге махсус комиссия уку-укыту документларын тикшерде, мәдрәсәдә укытуны оештыру эшләре белән танышты. Тикшерү азагында комиссия вәкилләре үзләренең тәкъдимнәрен һәм киңәшләрен җиткерделәр.

### КОРБАН АШЫ

12нче февраль көнне мәдрәсәдә Корбан ашы уздырылды. Бирегә мәдрәсә укучылары чакырылган иде. Мәҗлес күркәм үтте. Барлык катнашучылар канәгать калдылар.

### СЕССИЯДӘ КАТНАШТЫЛАР

21нче февральда мәдрәсә мөгаллимнәре Мамадыш шәһәр Совет утырышында катнаштылар.

### МӨНӘҖӘТЛӘР БӘЙГЕСЕНДӘ

Мәдрәсәнең беренче курс шәкерте Шәйдуллин Рафис 24нче февраль көнне Бөгелмә шәһәрендә узган мөнәҗәтләр бәйгесендә катнашты.

### КОНФЕРЕНЦИЯГӘ БАРА

Мәдрәсә җитәкчесе Габдрахман хәзрәт 2нче март көнне Яр Чаллыда Ак Мәчет бинасында узачак фәнни-практик конференциядә катнашачак. Ул Ислам диненең социаль процессларның тотрыклылыгын саклаудагы роленә багышлана.

# Безгә бүген ике яшь!

**Хөрмәтле газета укучылар! Иң кадерле, изге хисләребезне, теләкләребезне чагылдырган "Нәсыйхәт" газетасы ике яшен тутырды. 2 ел элек, нәкъ шушы көннәрдә, төгәлрәк – 25 февральдә, газетабызның беренче саны дөнья күргән иде. "Зур үс!"–шул сүзләр белән сөйгән сабый баланы әти-әнисе, туганнары үбәләр, күкрәкләренә кысып, аркасын сыйпыйлар, без дә бүген газетабызны тәбриклибез, саулык, бәхетле көннәр телибез!**



Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, яше кечкенә булуына карамастан, газетаның тормышы, төрле вакыйгаларга, төрле кичерешләргә бай. Әмма, күз курка, куллар эшли. Бүген газетабызның аена бер мәртәбә булса да бастырылып килүе–газета коллективының хезмәте. Алар үзләренең объективлыгы, гаделлегеге, җитешсезлекләргә битараф булмаулары белән безнең сәхифәләргә җан өрәләр.
Без уңышлы финишка этәрүче активистларыбыз белән горурлана алабыз. Бу шәхесләр "Нәсыйхәт"нең чишмә башында торучылар. Алар–баш мөхәррир Габдрахман хәзрәт Хәбибуллин, мөхәррир урынбасары Эльвира Хәбибуллина, җаваплы сәркатип Алсу ханым Спиридонова, дизайн һәм верстка өчен җаваплы Фирая Мингалиева, хәбәрчеләребез Әлфирә Хаҗиева, Рәйсә Рәхимҗанова, Мөнирә Нәбиуллина, Фатыйма Салихова, Сабирҗан Әхмәтҗанов, Ранил Талипов, Лена Муратова, Сөмбел Шәрифуллина.

Алар көннән-көн газетаның абруен үстерә, дәрәҗәсен күтәрә бара. Кешенең дөньяга карашын, идеалларын формалаштыруда зур тырышлык, теләк, үҗәтлек, нык ихтыяр көче сарыф итәләр. Иң зур шатлыгыбыз – мәдрәсә укучылары да бик матур, эчтәлекле шигырьләр һәм мәкаләләр язып, газетабызда бастыралар. Газетаның тарихи миссиясе зур. Чөнки халкыбызның бай рухи традицияләрен онытмыча яши, сайлаган кыйбласыннан тайпылмый. Газета төрле темаларны колачлап, һәр өлкәгә тиешенчә игътибар бирергә омтыла. Монда республикабыздагы дини яңалыклар, яшьләр, сәламәтлек, спорт, һәм гомумән җәмгыятьтәге күп проблемалар колачлана. Телебезне, гореф-гадәтләребезне, мәдәниятебезне саклап килүдә газетаның роле аеруча зур. Газета ярдәмендә күренекле имамнарыбызны, атаклы шәхесләребезне, сугыш ветераннарын беләбез, истә тотабыз.
Газетаның тоткан кыйбласы киң җәмәгатьчелек бурычлары белән уртак. Җәмгыятебездә җинаятьчелек, наркомания, әдәпсезлек һәм әхлаксызлык арта барган чорда газетабыз битендәге матур әдәби тел аша, хикмәтле сүзләр көче ярдәмендә кешеләрнең аңын, рухын сәламәтләндерү эше алып барыла. "Нәсыйхәт" газетасы вакыт белән бергә атларга тырыша. Тормыш вакыйгалары белән таныштырса, үзенең киңәшләрен дә бирергә онытмый. Газета битләрендә гыйбрәтле хәлләр белән танышу белән беррәттән, үрнәк шәхесләрнең язмышларын чагылдырган язмаларны да укырга мөмкин.
Газетаның һәр санында дип әйтерлек никах, ата-ана нәсыйхәте, әхлак мәсьәләләре яктыртыла, "гаилә институтлары" эшчәнлеген яхшырту, яшь буынны яңа шартларда тәрбияләү юнәлешендә каләм тибрәтелә. Газета гаделлеккә, мәрхәмәтлелеккә омтыла, аңа иҗади эзләнү хас. "Нәсыйхәт" район газеталары белән дә хезмәттәшлек итә, үз укучылары белән даими элемтәдә тора. Районыбызның төрле төбәкләрендә яшәүче кардәшләребезнең тормышы, алардагы яңалыклар белән һәрдаим кызыксынып, укучыларын таныштырып барырга тырыша.
Аерым хөрмәтне, олы рәхмәтебезне Камил әфәнде Хисмәтовка белдерәсебез килә. Ул безнең актив укучыбыз гына түгел, ә актив хәбәрчебез дә! Аның язмаларын укучыларыбыз да җылы кабул итте. Киләчәктә дә бергә булыйк! Ул әле тагын да зуррак үрләр яулар. Шулай ук безнең белән элемтәдә торучы авторларыбызның һәркайсының кулын кысып рәхмәт әйтәсе килә. «Нәсыйхәт» – ул безнең күмәк хезмәт җимеше һәм алга таба да җиң сызганып эшләсәк кенә аның тагын да олырак түгәрәк даталарын бәйрәм итәрбез.
"Нәсыйхәт"! Сиңа озын гомер телибез. Ешрак кил безнең өйләребезгә. Ә без исә, "аның һәр санына җан өрүче коллективыбыз, биргән вәгъдәләргә тугры калып, газетабызны кызыклырак, файдалырак итәргә омтылырбыз. Аллаһы боерса, киләсе елда да бар йөрәк җылысын, күз нурларын салып сезнең өчен эшләрбез, хөрмәтле укучыларыбыз!

ГАБДРАХМАН ХӘБИБУЛЛИН

## Туган көнең белән, “Нәсыйхәт”!

**Нурислам хәзрәт, Әхмәт Ясәви мәчете имам-хатыйбы, мәдрәсә мөгаллиме:**
–Әлеге газета өстендә эшләүчеләргә рәхмәт әйтәсем килә. Газетаның киләчәге дәвамлы һәм якты булса иде. Эчтәлекле һәм гыйбрәтле мәкаләләр теләп калам.
**Гыйззәтуллина Гадилә, IV курс талибәсе:**
–Газетаны туган көне белән тәбрик итәм. Ул җәмгыятьне агарту юнәлешендә зур эш башкара. Газета өстендә эшләүчеләргә иҗади уңышлар телим. Безне яңа, тирән эчтәлекле язмалары белән сөендереп торсыннар.
**Фәттәхова Флера, I курс талибәсе:**
–“Нәсыйхәт” газетасын һәрдаим укып барам. Мәкаләләре төпле һәм гыйбрәтле. Безгә, яңа гына дингә кереп баручыларга, үгет-нәсыйхәт бирә. Киләчәктә дә аңа зур уңышлар һәм иҗади үрләр телим.
**Абдуллина Миннур, II курс талибәсе:**
–“Нәсыйхәт” газетасын чыгаручыларга зур уңышлар телим. Киләчәктә дә безне гыйбрәтле язмалары белән сөендереп торсыннар иде. Газетаның укучылары күбәйсен, тиражлары артсын иде.
**Абдуллина Мәүсия, II курс талибәсе:**
–Очраклы гына кулыма “Нәсыйхәт” газетасы килеп эләкте. Андагы язмаларны мин игътибар белән укыдым. Әлеге вакыйга мине дин белән кызыксынырга тагын да ныграк этәрде. Шулай итеп, мин мәдрәсәгә укырга керергә булдым. Шуңа күрә барысы өчен дә газетага рәхмәтемне белдерәсем килә. Аңа зур уңышлар телим.
**Әхмәтҗанова Гөлнур, мәдрәсә талибәсе:**
–Газетага алдагы елларда да зур уңышлар телим. Күп укучылары булсын, тиражлары артсын. Безне яңадан-яңа кызыклы язмалары белән сөендереп торсын.
**РЕДАКЦИЯДӘН. Җылы сүзләрегез, матур котлауларыгыз өчен бик зур рәхмәт, хөрмәтле укучыларыбыз! Сезнең шундый тәбрик сүзләрен ишеткәч, безгә дә эшләве рәхәт тә, җиңелрәк тә! Киләчәктә дә бездән аерылмассыз дигән өметтә калабыз.**

# ДӨНЬЯ ЯҢАЛЫКЛАРЫ



### ТАТАРСТАН МӨФТИЯТЕ 2013 ЕЛНЫ МӘРҖӘНИ ЕЛЫ ДИП ИГЪЛАН ИТТЕ.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте 2013 елны “Шиһабетдин Мәрҗани” елы дип игълан итте. Татар дин белгече, фәлсәфәче, тарихчы, педагог, археолог Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына быел 195 ел.
Диния нәзарәте Мәрҗанинең мирасын өйрәнүгә кызыксынуны арттыру, аның тарафдарларының хезмәтләрен өйрәнү һәм татар халкы дин белгечләренә әһәмиятне арттыру йөзеннән, ел дәвамында төрле түгәрәк өстәлләр, фәнни конференцияләр, бәйгеләр уздырырга, китаплар чыгарырга планлаштыра.

### РОССИЯ МӨСЛИМӘЛӘРЕ БЕРЛЕГЕ РФ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫНДА РӘСМИ ТЕРКӘЛДЕ.

“Россия Мөслимәләре берлеге” иҗтимагый оешмасы РФ Юстиция министрлыгында рәсми теркәлде. Әлеге оешма Россия Мөфтиятләре советы резиденциясендә урнашачак. Аның составында илледән артык вәкиллек һәм филиал бар. Россия Мөслимәләре берлеге рәисе булып Наилә Җиһаншина тора. Бу хакта Россия Мөфтиятләре советы матбугат хезмәте хәбәр итә.

### СҮРИЯГӘ ТӘҮГЕ ЯРДӘМ КИЛДЕ

«Интерфакс»тан алынган хәбәрләргә караганда, РФнең Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының (ГТХМ) беренче очкычы Ил-62 Сүриягә барып җиткән.
“Ике очкычның беренчесе бүген, ягъни 19 февральдә Мәскәү вакыты белән 14 сәгать 36 минутта Латакия каласына килеп җитте. Аның бортында гуманитар ярдәм һәм “Центрспас” медиклары, психологлар»,–дип билгеләп узганнар ГТХМда.

### ХӘЛӘЛ СТАНДАРТЫ: ТЕОРИЯ ҺӘМ ТӘҖРИБӘ

15 февральдә Россия Ислам университетында Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең “Хәләл” стандартлар комитеты катнашында, “Хәләл” стандартлары: теория һәм тәҗрибә” дип аталган “түгәрәк өстәл” уздырылды. Әлеге чарада комитет хезмәткәрләре һәм уку йорты мөгаллимнәре Россия һәм дөнья күләмендәге хәләл индустриягә багышланган чыгышлар ясалды.
Шуны да әйтергә кирәк, “түгәрәк өстәл”дән соң, комитет РИУ белән берлектә хәләл индустриягә багышланган курслар оештыра. Курслар хәләл товарлар җитештерүчеләр һәм сатучылар өчен махсус үткәрeләчәк, дип хәбәр итә **“Хәләл” стандартлар комитеты.**

### КАЗАХСТАНДА ЯҢА БАШ МӨФТИ САЙЛАНДЫ

41 яшьлек Иржан Мәямирев сишәмбе көнне Астанада үткәрелгән Диния нәзарәтенең чиратсыз тыш корылтаенда Казахстанның яңа баш мөфтие итеп сайланды. Аңа кадәрге баш мөфти Габсаттар Дәрбисали үз теләге белән мөфти вазыйфасын үтәүдән туктады, дип хәбәр итте Алма-Атаның Үзәк мәчете сайты.

**Яңалыклар tatar-islam.com мәгълүмати агентлыгыннан алынды.**

# Рибаның гөнаһысы

**1.Аллаһының ләгънәте төшә.**
Рәсүлебез (с.г.в.с.) риба ашаучыны да, бирүчене дә, язучыны да, аларның килешүенә шаһәдәт биргән ике кешене дә ләгънәтләде. Алар бөтенесе дә гөнаһыда тигез”,–диде. **(Мөслим, 2995 нче хәдис)**
**2.Риба–бозыклыкның бозыгы.**
“Рибаның 70 төре бар. Аның иң аз гөнаһылы төре дә үз анасы белән никахлашып яшәгән кебек”, – диде рәсүлебез (с.г.в.с.) **(Ибн Мәҗәһ, 2265 хәдис)**
**3.Риба ахыр чиктә бөлгенлеккә китерә.**
Аллаһы Тәгалә әйтте: “Аллаһы рибаның файдасын бетерер, ә сәдакаларның файдасын хуҗаларына арттырып кайтарыр”. **(“Бәкара” сүрәсе, 276 нчы аять)**
**4.Риба зинадан яман.**
«Белә торып, бер көмеш акчалык кына риба малын ашау 36 зина кылудан яманрак”, – диде рәсүлебез (с.г. в.с.) **(Имам Әхмәд, 20951 нче хәдис)**
Газиз кардәшләр! Күпләре без белми яки гөнаһысын вак-төяккә санап, процентлы кредитка өйләр салды, машиналар һ.б. җиһазлар алды. Боларга бүген нишләргә? Бердәнбер юл–тәүбә итәргә һәм кабат ошбу гөнаһны кабатламаска. Раббыбыз Коръәндә әйтте: “Кемгә Раббысының вәгазе җитеп, риба эшләрен ташлады, риба отышын алмасын. Кем дәвам итсә, алар җәһәннәм кешеләре, һәм анда мәңге калучылар”. **(“Бәкара” сүрәсе, 275 аять)**
Сак булыйк! Алдашмыйк! Рибадан уттан сакланган кебек сакланыйк!

**Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән сау - сәламәт яшәү өчен дөрес тукланырга кирәк икәне һәрберебезгә мәгълүм.**

# Мөселманга хас ашау һәм эчү

Ә дөрес туклану үз чиратында санап бетергесез аспектларга һәм сәбәпләргә бәйләнгән: дини, психологик, физио-анатомия, гигиена һәм тыйб (медицина) аспектлары, биохимия, төп туклыклы матдәләр арасындагы чагыштырма нисбәт, организмны тиешле күләмдә генә энергия белән тәэмин итү сораулары һәм башкалар. Безнең максат–ислам дине күзлегеннән чыгып, хәзерге заман фәннәре нигезендә иң киң таралган дөрес һәм дөрес булмаган ашау һәм эчү гамәлләренә тукталу. Аз гына читкә китеп шуны әйтәсе килә: әгәр гамәлебезне Аллаһы Тәгалә исеме белән һәм аның ризалыгын өмет итеп башкарсак, бу дөньяда безнең һәр гамәл савап булырга мөмкин.

Иң башта санап киткән аспектларга һәм сәбәпләргә кагылган гомуми сорауларны ачыклыйк. Әбү Хөсәен ибн Габдулла ибн Гали ибн Сина (Әбүгалисина) әйтүе буенча: “Иртәнге ашны үзең аша, көндезге ашны дустың белән бүлеш, ә кичке ашны дошманыңа бир!” Бу бәхәсләшергә урын калдырмыйча бүгенге фән белән исбатланган фикер. Әйе, иртәнге һәм төшке ашларның энергиясе безнең хәрәкәткә китә (эш, уку, физкультура һ.б.), ә кичке аш безнең тән авырлыгына... Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә, димәк без үзебезгә үзебез дошман булып чыгабыз, ягъни гәүдә авырлыгының һәр артык килограммы безнең гомернең уртача бер елын кыскарта һәм авыруларга бирешмәү сәләтен (иммунитет) кимәтә. Ә корсактагы артык һәр кг гомерне уртача 3 елга кимәтә...

Пәйгамбәребез(с.г.в.)түбәндәге хәдистә болай дигән: “Хәрам ризык исәбенә үскән бәдән җәһәннәм уты өчендер.” Бу безнең ашау-эчү сорауларында хәл ителгән булырга тиеш. Ә хәрам ризыклар һәм эчемлекләр турында ислам шәригатендә яхшы аңлатылган булу сәбәпле, анысына тукталмадык. Пешекченең пакъ тән (геселле булуы ), изге күңел һәм әгүзү - бисмилләһи әйтеп аш (ризык ) һәм эчемлек әзерләве шулай ук мөһим шарт булып тора. Ни өчен? Менә шундый халәттәге пешекченең генә ашы һәм эчемлеге күңелгә хуш һәм тәмле була... Бу безнең җәмгыятьтә әле ирешелмәгән үр. Хәләл ризык кибетләре һәм базарлары оештырып моңа ирешә алабыз. Әйе, әлегә җитештерү тармаклары да бу сорауга әһәмият бирми. Дөресен генә әйткәндә, мөхтәсибәт һәм мөфтият җитештерү һәм сәүдә оешмалары белән әлегә житәрлек дәрәҗәдә эшләми.

Югарыда әйтелгән хәдис нигезендә хәрам ризык безнең сәламәтлекне какшатудан башка иманыбызны да зәгыйфьли. Бу шулай ук тыйб һәм гыйльме рух (психология) фәннәре белән исбатланган: хәрам ризыклар һәм эчемлекләр (бигрәктә хәмер дигәннәре) безнең күңелләрдәге тормышка булган мәхәббәтне, азмыкүпме изге хисләрне һәм дә иманыбызга булган тәкъвалыкны үтерә...

Гадәттә ризыкны ашау тамак туйдыру максатыннан гына чыгып башкарыла. Бу бик үк дөрес булмаган гамәл. Ни өчен? Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән безнең организмның халәте ризык һәм эчемлекләр белән нык бәйләнгән. Математиклар күзлегеннән бу аңлата: ризык һәм эчемлекләр – бәйсез (организмга) һәм үзгәрүчән (безнең теләк белән зурлык (х-аргумент) икәнен, ә безнең организм бу зурлыкның функциясе (у – функция). Ягъни азыкны һәм эчемлекләрне без теләсә кайсы вакытта төрләндерә алабыз, ә организмның халәте ашаган ризык һәм эчемлеккә карап үзгәрә. Теләсә нинди авыруның башлангыч чорында безнең организмда табигый балансның какшавы ятуы да безгә мәгълүм... Әгәр бәрәкәтлелек принцибыннан чыгып башкарсак, безнең ашау һәм эчү гамәле сәламәтлек өчен зур әһәмияткә ия икәнен күрәбез.

Ашар алдыннан: “Бисмилләһир-рахмәнир рахим. Аллаһуммә бәрик ләнә фимә разәктәнә үә кыйнә газәбәннар” (рәхимле, рәхмәтле Аллаһ исеме белән башлыйм. Йә Раббым, безнең ризыгыбызны бәрәкәтле ит һәм безне җәһәннәм утыннан сакла ) дип әйтергә мөмкин. Ә аннары үзебезнең телдә булса да: “Йә Раббым, безнең ризыкларыбыз безгә шифа гына булса иде!– дип сорарга кирәк. Вәкарь саклап, тиешле тизлектә ашау - эчү сөннәт санала. Ашыгып ашау, яки азыкны 5-6 тапкыр гына чәйнәп йоту киң таралган начар гадәтләрнең берсе булып тора. Азыкны яхшылап чәйнәргә кирәк икәне галимнәрнең фәнни хезмәтләрендә ( диететика) күренә:

–азыкның төренә һәм катылыгына карап, аны 15тән алып 30 тапкырга чаклы чәйнәргә кирәк. Азыкны тиешле күләмгә чаклы тураклarga һәм йомшартырга ашказанының тешләре юк;

–тиешле чәйнәү санында һәр төрле азык үзенә авыз куышлыгы сeләгәен сеңдерә, ә бу үз чиратында ашказанына бик зур булышу икән. Икенче яктан безнең бәрәкәтлелек принцибы да бик яхшы үтәлә;

–диететика фәне кагыйдәләрнең берсе–әгәр мөмкинлегең булса, сыек ризыкны күп ашарга тырышма дип аңлата. Чөнки аны чәйнәп йотмыйбыз ягъни ашказанына тиешле тәртиптә (селәгәйдән башка ) әзерләмичә йотабыз.

Ашаганда азыкка хөрмәт белән карарга, әрәм - шәрәм итүгә юл куймаска. Мөселманнарның ашау әдәбе буенча күп ашау–убырлык.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) ашказанын өчкә бүлергә дип өйрәтә : 1/3 дә азык, 1/3 дә сыеклык (су) һәм калган 1/3 дә һава булырга тиеш. Табын янынннан туяр - туймас кузгалып китү – сөннәт гамәл, ә инде туйганнан соң ашау һәм эчү – хәрам гамәл. Безнең бу гамәлләр диететика фәне тарафыннан исбатланган ... Әгәр ашэчемлек кайнар икән, аны өреп суыту мәкрүһ гамәл. Чөнки өреп чыгарылган һава углекислый газга бай булу сәбәпле ашау-эчүнең физиологик процессларына негатив (кире ) тәэсир итә дип аңлаталар диетологлар.

Ашап бетергәч, ризыкландырган өчен Аллаһы Тәгаләгә: “Әлхәмдүлилләһиллләзии әтгамәнии үә сәкании үә җәгәлнии минәл мусchallенгә...

Ашап бетергәч, ризыкландырган өчен Аллаһы Тәгаләгә: “Әлхәмдүлилләһил-ләзии әтгамәнии үә сәкании үә җәгәлнии минәл муслимииин” (Безгә ризык, су биргән һәм безне мөселман иткән Аллаһыга барча мактаулырыбыз булсын)”,–диргә кирәк. Соңыннан кулларны юу һәм авызны чайкау яки тешләрне теш щёткасы белән чистарту сөннәт гамәллләрдән санала.

Башта санап киткән аспектларга һәм сәбәпләргә турыдан-туры кагылган сораулар турында берничә сүз. Дөрес туклану турындагы фәнни тезислар:

–газ өстендә пешерелгән теләсә нинди азык безне үлемгә тизрәк якынайта икән. Икенче төрле әйткәндә безгә кирәк булган “ кояш энергиясен” файдалана алмыйбыз булып чыга. Ни өчен? Температура +42 С һәм югарырак булганда аксымнарның денатурациясе башлана, суның безгә кирәк булган структурасы бозыла, азыкта шулай ук безгә кирәк булган витаминнар бик нык кими һәм башка негатив процесслар ...

–безнең организм өчен терлек аксымнарына (ит, йомырка, сөт һ.б.) караганда үсемлек аксымнарының тагын да яхшырак булуы исбат ителде ;

–борынгы медицинага нигез салучыларның берсе Әбүгалисина: “Әгәр яшьлегеңне саклыйсың килсә, бал аша!”– дип язган. Ул аны аеруча 40 яшьтән узган кешеләргә тәкъдим иткән;

–сөт һәм эремчекне күп ашарга кушмыйлар. “Сөтне файдалы азык диләр, ә тарих киресен сөйли,”– ди диететика фәне. Кем сөт ярата, ул суык тию, грипп, астма, бронхит, үпкәләр ялкынсынуы, туберкулёз һәм башка авырулар белән ешрак авырый икән. Диететика фәне моның сәбәпләрен бик яхшы аңлата...

–ит, балык, йомырка, ягъни аксымга бай ризыкларны крахмалга (ипи, бәрәңге, дөге, борчак һ . б.) бай ризыклар белән бер үк вакытта ашарга кушмыйлар.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә, иманыбызның тәкъвалыгын күтәрү юлында безнең ашау-эчү гамәле дә зур әһәмияткә ия. Иманыбызга зәгыйфьлек бирүче ризык һәм эчемлекләрдән табыннарыбыз чиста булсын!

...............................

**КАМИЛ ХИСМӘТОВ,**

мәдрәсәнең 1нче курс шәкерте, гер спорты буенча Европа һәм дөнья чемпионы.

## Сорау-жавап

**–НӘРСӘ УЛ МӘЗҺӘБ?**

–Мәзһәб–гарәп сүзе “зәһәбә” дигән фигыльдән чыккан, урын-вакытны аңлаткан исем. “Зәһәбә” китте, ә “мәзһәб” бара торган юлны аңлата.

Диндәге “мәзһәб”–дин галимнәренең Коръән һәм хәдис дәлилләренә таянып чыгарган фәтвәләр җыентыгы. Ислам тарихында башта алар түгәрәк, оешма, мәктәп булып хасил булды. Соңрак, бу оешма, мәктәпләргә кушылгач, “мәзһәб” дип йөртелә башладылар.

**–1 КАПЧЫК БӘРӘҢГЕНЕ 2 КАПЧЫК ИГЕНГӘ АЛЫШТЫРЫРГА ЯРЫЙМЫ?**

–Ярый. Икесе дә үлчәмле яки күләмле булсалар да, бер төрле әйбер түгел. Ләкин кулдан-кулга булырга тиеш, ягъни бурычка ниндидер вакыт үткәч бирергә сөйләшү ярамый. Бу рибага керә.

**–ДОГА КЫЛГАННАН СОҢ КУЛЛАР БЕЛӘН БИТНЕ СЫПЫРУ НИНДИ ГАМӘЛ?**

–Моңа карата берникадәр күләмдә зәгыйфь хәдисләр бар. Әмма алар бер-берсен ныгытып киләләр. Мисал өчен: Тирмизида китерелә, Гомәр, аннан Аллаһы Тәгалә разый бусын, әйтте: “Пәйгамбәребез, гәләйһиссәләм, дога кылганда кулларын күтәрә иде, һәм аларны төшергәнче битен сыпыра иде”.

Сайб Язидтән, аннан Аллаһы Тәгалә разый бусын, китерелә: “Пәйгамбәребез, гәләйһиссәләм, дога кылганда кулларын күтәрә иде һәм алар белән битен сыпыра иде”.

**–ТАЛАКТАН (АЕРЫЛЫШУ СҮЗЕ) СОҢ ХАТЫННЫ НИЧЕК КИРЕ КАЙТАРЫП БУЛА?**

–Талак берничә төргә бүленә. Әгәр дә ир хатынына “талак” дип бер яки ике мәртәбә әйткән булса, ул аны сүзләр белән һәм гамәлләр белән кире кайтара ала. Мисал өчен: “Син минем хатыным”, яки “Мин сине кире кайтарам”,–дигән сүзләр белән. Яки аны иркәләү, сөю, үбү, якынлык кылу ише гамәлләр белән.

# Әби хаты

–Йә, сеңлем, ничек хәлләрең бүген?

–Яхшы, доктор, күпкә яхшырак,– дип җавап бирде Сиринә, карашын читкә юнәлтеп.– Мине тиздән чыгарасызмы?

–Әлегә берни дә әйтә алмыйм. Кәефең көн саен диярлек үзгәрә. Чыгарырга гына уйлыйм да, тик син үзгәрәсең, сеңлем.

–Димәк, мин тагын сезнең төссез дөньягызда калам.

–Сеңлем, барысы да синнән тора. Теләгең дә юк түгел күңелеңдә, ләкин ахыргача син сау түгел. Физик яктан син сәламәт, әмма психикаң какшый, сеңлем.

–Миңа авыл кирәк, Шәүкәт Кадырович. Анда кайтсам, мин тереләчәкмен. Безнең авыл һавасы гына ни тора бит. Ә сез мине аңлап җиткермисез.

–Аңлыйм, сеңлем, әмма чыгара алмыйм. Тагын бер атна син безнең хастаханәдә ятачаксың әле, анары карарбыз.

Сиринә докторның сүзләрен тыңлап бетермичә, икенче якка борылып ятты. Шәүкәт Кадырович берничә минут көтте, Сиринә генә аңа карап бер сүз дә әйтмәде. Тагын кәефе төште, дигән уйлар белән палатадан чыгып китте.

Сиринә, вазадагы суны алыштырганнан соң, өстәл янына килеп утырды. Көндәлегенә язмаганга берәр атналап вакыт узган, соңгы язмасында ул балачагын, беренче мәхәббәтен һәм әнисенең үлемен язган. Хәзер Сиринә шатлыклы вакыйгаларны көндәлегенә теркәргә булды. Хәреф арты сүз, сүз арты җөмлә китте, шулай итеп тулы бер мәкалә туды. «Исәнме, кадерле көндәлегем! Сиңа язмаганга нәкъ бер атна вакыт узган, тик бер атна эчендә әллә ни яңалыклар күңелемдә калмады. Мин һаман да хастаханәдә ятам. Монда бик күңелсез... Урамда әбиләр чуагы булуына карамастан, минем күңелемдә болытлы көн. Шигырьләр туа кайчак күңелемдә, ләкин мин аларны язып куярга өлгермим, чөнки алар хәтеремдә сакланмыйлар, шуңадыр бәлки бу көннәрдә тубы суга төшеп киткән Әминә кебек йөрим. Мине бары тик яраткан авылым гына яшәтә. Сагындым су буйларын, сердәшче талларымны, тын гына агып утыручы чишмәләрне һәм иң мөһиме–әбиемне. Минем монда ятканымны



белсә, аңа бик авыр булыр иде. Ярый әле апа әбигә шалтыратып, Сиринә икенче шәһәргә, эшләре буенча китте дип әйткән. Аллага шөкер, ул исән-сау. Әбине тизрәк күрәсе, кочып, туйганчы елыйсы килә. Кызганыч, әлегә бу хыял булып кала бирә. Әмма мин өметемне өзмим. Мин кайтачакмын авылыма, күрәчәкмен әбиемне һәм аны кочып елаячакмын. Менә шундый хәлләр, көндәлегем, шулай яшәп ятыш. Ичмасам син бар күңелемдәге сагышларны бушатырга. Рәхмәт сиңа, дустым, бик зур рәхмәт!
25.09.1997.

Ниһаять, ул күңелендә тынычлык тойды. Аңа рәхәт, күңелендә әйтә алмаслык җиңеллек аның, ул бәхетле. Уйларына бирелеп утырганда, ишектә психолог Резидә Шәфкатовна күренде.

–Исәнме, Сиринә, ничек хис итәсең үзеңне?

–Яхшы.

–Мин бик шат. Күрәм, син тагын язу эшенә утыргансың.

–Әйе, бүген көндәлегемә яздым әле.

–Нәрсә турында яздың инде?

–Хыялым турында.

–Бик әйбәт, димәк, алга китеш бар. Үткән атнада без синең белән балачагың һәм авылдагы тормышың хакында сөйләшкән идек. Тик син шәһәрдәге тормышыңны сөйләүдән баш тарттың, сәбәбе нәрсәдә, Сиринә?

–Минем ул көннәргә кире кайтасым килми.

–Мәхәббәтең җаваплы идеме?

–Әйе. Мин яраткан кеше хәзер Татарстанда түгел.

–Аны сагынасыңмы?

–Әлбәттә, мин аны һаман да яратам,–диде Сиринә тын гына һәм урындыктан торып, тәрәз янына таба китте.–Мин аның белән биш ел элек, әбигә кунакка кайткач таныштым. Ирек юмор хисле, сөйкемле һәм ачык күңелле ул, ягымлы күзләрендә дөньяның барлык матурлыгын күреп була, миңа аның белән беркайчанда күңелсез булмады.

–Син Ирек белән хәзер аралашасыңмы?

–Юк. Безнең аралар салкынайды. Барысына да мин генә гаепле, әгәр дә мин аны ахыргача тыңлап бетергән булсам, ул хәл булмас иде.

–Нәрсә булды соң арагызда? Сөйли аласыңмы?

–Юк, мин теләмим.

–Сиңа яраны күңелендә тотмаска киңәш итәм. Сөйләсәң, яхшырак булачак, ышан миңа.

–Мин теләмим икән, сез мине мәҗбүр итә алмыйсыз. Шулаймы?

–Әйе, шулай. Минемчә бүгенгә җитеп торыр. Сөйләшүне иртәгесенә калдырыйк.

.................................

**ФАЯГӨЛ ТАЛИПОВА.**

**Көек-Ерыкса авылы.**
**(Дәвамы киләсе санда)**

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.**
**Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.**
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета “Татмедиа” ААҖнең Мамадыш муниципаль районы”Нократ” мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 250 данә.**